**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Күкшел авыл җирлеге Башлыгы**

**Карары**

**08 ноябрь 2021 ел** **№3**

**«Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге Уставның 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 18 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Мәчкәрә авылы Октябрь тыкрыгы, 11 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

2. 2021 елның 18 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Мәчкәрә авылы, Октябрь тыкрыгы, 11 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: “Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар,1 төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала , Татарстан Республикасы

Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Мәчкәрә авылы , Октябрь тыкрыгы юлларына вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Мәчкәрә авылы, Луговая урамы буенча вак таш җәелгән юлларның профилен төзәтү (килешү буенча түләү);

- Су башнясы өчен насос алу (килешү буенча түләү);

- Янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);

- Мәчкәрә авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү);

- Зиратларны карап тоту, материаллар алу, койма урнаштыру, инвентарь алу (килешү буенча түләү);

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р. Р. Хәмидуллин

ОГРН 1021607753298 ИНН 1623002022